КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 21 декабрь г.Казань № 1261

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы норматив хокук актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү һәм Татарстан Республикасы норматив хокук актларына экспертиза үткәрү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1182 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы норматив хокук актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү һәм Татарстан Республикасы норматив хокук актларына экспертиза үткәрү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1182 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 22 июль, 511 нче; 2014 ел, 5 декабрь, 948 нче; 2016 ел, 4 июль, 457 нче; 2019 ел, 25 июнь, 512 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге ФЗ-184 номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында булган мәҗбүри таләпләр билгеләү һәм аларны куллануны бәяләү һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертиза ясау турында» 2014 елның 7 мартындагы ТРЗ-14 номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы норматив хокук актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү һәм Татарстан Республикасы норматив хокук актларына экспертиза үткәрү тәртибендә:

1.1 һәм 1.2 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Бу Тәртип «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге ФЗ-184 номерлы Федераль законның 263-3 статьясы, «Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында булган мәҗбүри таләпләр билгеләү һәм аларны куллануны бәяләү һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертиза ясау турында» 2014 елның 7 мартындагы ТРЗ-14 номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә эшләнде һәм түбәндәге Татарстан Республикасы законнары проектларының, Татарстан Республикасы Президенты указлары проектларының, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары проектларының, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең бүтән органнары норматив хокук актлары проектларының (алга таба – норматив хокук актлары проектлары) җайга салу йогынтысын бәяләүне үткәрүгә бәйле мөнәсәбәтләрне җайга сала:

а) эшмәкәрлек һәм башка икътисадый эшчәнлекне гамәлгә ашыруга бәйле булган, дәүләт контроле (күзәтчелеге) кысаларында үтәлеше бәяләнә торган яңа мәҗбүри таләпләрне, административ җаваплылыкка җәлеп итүне, лицензияләр һәм башка рөхсәтнамәләр бирүне, аккредитацияләүне, продукциянең туры килү-килмәвен бәяләүне, бәяләүнең һәм экспертизаларның башка формаларын билгели торган, Татарстан Республикасы норматив хокук актларында элегрәк каралганнарга үзгәреш кертә яки гамәлдән чыгара торган;

б) эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен яңа йөкләмәләр һәм тыюлар билгели торган, Татарстан Республикасы норматив хокук актларында элегрәк каралганнарга үзгәреш кертә яки гамәлдән чыгара торган;

в) эшмәкәрлек һәм башка икътисадый эшчәнлекне гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы Татарстан Республикасы норматив хокук актларын бозган өчен җаваплылык билгели торган, аңа үзгәреш кертә торган яки аны гамәлдән чыгара торган;

шулай ук эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыруны нигезсез рәвештә кыенлаштыра торган нигезләмәләрне ачыклау максатларында, эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Президенты указларына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларына, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең бүтән органнары норматив хокук актларына (алга таба – норматив хокук актлары) экспертиза үткәрү тәртибен билгели.

Норматив хокук актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү эшмәкәрлек һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектлары өчен артык бурычлар, тыюлар һәм җаваплылык кертә торган яки аларны кертүгә этәрә торган нигезләмәләрне, шулай ук эшмәкәрлек эшчәнлеге һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектларының һәм Татарстан Республикасы бюджетының нигезләнмәгән чыгымнары барлыкка килүне китереп чыгара торган нигезләмәләрне ачыклау максат-

ларында үткәрелә.

1.2. Бу Тәртипнең нигезләмәләре түбәндәгеләрнең җайга салу йогынтысын бәяләүгә бәйле мөнәсәбәтләргә карата кулланылмый:

1) төбәк салымнарын, шулай ук федераль салымнар буенча салым ставкаларын билгели торган, аларга үзгәреш кертә, туктатып тора торган, аларны гамәлдән чыгара торган Татарстан Республикасы законнары проектларының;

2) бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган Татарстан Республикасы законнары проектларының;

3) түбәндәге норматив хокук актлар проектларының:

а) продукциягә (товарларга, хезмәт күрсәтүләргә) җайга салына торган бәяләр (тарифлар), мондый бәяләргә (тарифларга) сәүдә өстәмәләре (өстәмә бәяләр) өлкәсендә бәя билгеләү тәртибен билгели торган федераль законнар нигезендә дәүләт тарафыннан җайга салынырга тиешле продукциягә (товарларга, хезмәт күрсәтүләргә) бәяләрне (тарифларны), мондый бәяләргә (тарифларга) сәүдә өстәмәләрен (өстәмә бәяләрне) билгели торган, аларга үзгәреш кертә торган һәм аларны гамәлдән чыга торган;

б) гадәттән тыш хәлләр режимнары гамәлдә булган чорда табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү максатларында эшләнгән.»;

3.2 пункттагы 3.2.4 пунктчасында:

алтынчы абзацта «инвестиция» сүзен «башка икътисадый» сүзләренә алмаштырырга;

җиденче абзацта «инвестиция» сүзен «башка икътисадый» сүзләренә алмаштырырга;

унынчы абзацта «инвестиция» сүзен «башка икътисадый» сүзләренә алмаштырырга;

унберенче абзацта «инвестиция» сүзен «башка икътисадый» сүзләренә алмаштырырга;

3.4 пункт үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин